| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**Постановление** | **Карар**

09.11.2018 Казан ш. № 10-32/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 17 ноябрендәге 10-71/кс номерлы карары белән билгеләнгән «Восток-Энерго» производство-коммерция оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2019 елга эчәргә яраклы суга озак вакытка исәпләнгән тарифларны үзгәртү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны билгеләү регламентын раслау турында» 2014 елның 16 июлендәге 1154-э номерлы боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2018 - 2020 елларга «Восток-Энерго» производство- коммерция оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга тарифлар билгеләү турында» 2017 елның 17 ноябрендәге 10-71/кс номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәиснең беренче урынбасары А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының 2017 елның 17
ноябрендәге 10-41/кс номерлы карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының2018 елның 9 ноябрендәге
10-32/кс номерлы карары редакциясендә)
1 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Восток-Энерго» производство- коммерция оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2018 - 2020 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, эчәргә яраклы суга тарифлар

| т/б № | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 30 июненә кадәр | 2020 елның 1 гыйнварыннан алып 2020 елның 31 декабренә кадәр |
| | Чистай муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Восток-Энерго» производство- коммерция оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 27,31 | 27,31 | 27,01 | 27,01 | 27,01 | 28,34 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән) | 23,14 | 23,14 | 22,51 | 22,51 | 22,51 | 23,62 |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерым күрсәтелә

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2017 елның 17 ноябрендәге 10-41/кс номерлы карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
2018 елның 9 ноябрендәге 10-32/кс номерлы карары редакциясендә)
2 нче кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Восток-Энерго» производство- коммерция оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2017 – 2019 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, эчәргә яраклы суга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме<br>тариф төре | Ел | Операцияләр чыгымнарының башлангыч күрсәткече | Оперцияләр чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | су югалту дәрәҗәсе | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | процент | процент | процент | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | «Восток-Энерго» производство-коммерция оешмасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Эчәргә яраклы су | 2018 | 873,26 | 1 | - | 2,5 | 1,1 |
| | | 2019 | 903,36 | 1 | - | 2,5 | 1,1 |
| | | 2020 | 924,12 | 1 | - | 2,5 | 1,1 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге